**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2858**
**23.04.2021**

Яр Чаллы шәһәренең «М.Ш. Бибишев исемендәге «Витязь» Олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешнең 4 пунктчасы, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмәнең 5 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы карары белән расланган Муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «М.Ш. Бибишев исемендәге «Витязь» Олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.
2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 23 апрелендәге
2858 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең
«М.Ш. Бибишев исемендәге «Витязь» Олимпия резервы спорт мәктәбе»
муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә
тарифлар

| № т/б | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Хезмәттән файдаланучылар | Хезмәтнең бәясе (сум) |
|---|---|---|---|---|
| I. Объект: «Дулкын» бассейны. Мәдәни-массакүләм һәм спорт-сәламәтләндерү чараларын оештыру һәм үткәрү | | | | |
| 1. | Йөзү | 45 минут | Балалар | 150,00 |
| | | | Зурлар | 200,00 |
| 2. | Йөзү (абонемент буенча бер тапкыр бару) | 45 минут | Балалар | 130,00 |
| | | | Зурлар | 180,00 |
| 3. | Сәламәтләндерә торган йөзү | ай | Балалар | 2000,00 |
| 4. | Спорт-сәламәтләндерә торган йөзү | ай | Балалар | 1400,00 |
| 5. | Сауналы бассейн (бер тапкыр бару) | 90 минут | Балалар | 300,00 |
| | | | Зурлар | 400,00 |
| 6. | Сауналы бассейн (абонемент буенча бер тапкыр бару) | 90 минут | Балалар | 250,00 |
| | | | Зурлар | 350,00 |
| 7. | Йөзү. Еллык абонемент (расписание буенча) | ел | Балалар | 15750,00 |
| | | | Зурлар | 21000,00 |
| 8. | Йөзү. Абонемент. (расписание буенча) | ай | Балалар | 2250,00 |
| | | | Зурлар | 3000,00 |
| 9. | Бассейнга керү 45 минут (бер тапкыр, укучылар төркеме өчен – укытучы белән физкультура дәресләре) | 45 минут | 1 кешегә | 100,00 |
| 10. | Бассейнга керү 45 минут (бер тапкыр, югары уку йортлары, техникумнар, училищеларда укучылар төркемнәре өчен) | 45 минут | 1 кешегә | 120,00 |
| 11. | Йөзү бассейнының тренажер залы | 45 минут | 15 кешегә кадәр | 800,00 |
| 12. | Йөзү бассейнының спорт залы | 45 минут | 15 кешегә кадәр | 800,00 |

| II. Объект: «Витязь» бинасы | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Атлетика гимнастикасы залы | ай (irekле йөрү) | - | 1300,00 |
| | | 60 минут | - | 150,00 |
| 2. | Кросс-фит залы | ай | - | 1300,00 |
| | | 60 минут | - | 150,00 |
| 3. | Көрәш келәмнәре белән зал | ай | - | 1300,00 |
| | | 60 минут | - | 150,00 |
| 4. | Өстәл теннисы | 60 минут | - | 200,00 |
| 5. | Массакүләм спорт чаралары үткәрү өчен уен залы | 60 минут | 40 кешедән артык | 2500,00 |
| 6. | Массакүләм спорт чаралары үткәрү өчен уен залы (10 сәгать һәм күбрәк) | 60 минут | 40 кешедән артык | 1600,00 |
| 7. | Массакүләм спорт чаралары үткәрү өчен уен залы (бер тәүлеккә) | 24 сәгать | 40 кешедән артык | 36000,00 |
| 8. | Спорт көрәше бүлекчәсенең көрәш залы | 45 минут | 30 кешегә кадәр | 800,00 |
| 9. | Көрәш залы | 45 минут | 15 кешегә кадәр | 600,00 |
| 10. | Футбол кыры (стадион) | 60 минут | - | 1500,00 |
| 11. | Чишенү бүлмәсе | 60 минут | 15 кешегә кадәр | 150,00 |
| 12. | Грек-рим көрәше буенча түләүле спорт-сәламәтләндерү хезмәтләре | ай (60 ар минутлы 8 дәрес) | балалар, укучылар, студентлар | 1500,00 |
| 13. | Спорт комплексы залларында түләүле спорт-сәламәтләндерү хезмәтләре | ай (60 ар минутлы 8 дәрес) | балалар | 2400,00 |
| 14. | ГТО тапшыру мәйданчыгы | 60 минут | - | 500,00 |
| 15. | Тернәкләндерү үзәге (ял бүлмәсе, купель, массаж креслосы, сауна) | 60 минут | 6 кешегә кадәр | 800,00 |
| 16. | Балигъ булганнарга, балигъ булмаганнарга вакытлыча яшәү урыны бирү | тәүлек | бер кешедән | 350,00 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева